**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОАРЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Школьная ул., дом 30
с.Новый Арыш, 422656

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА АРЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Мәктәп урамы, 30нче йорт,
Яңа Арыш авылы, 422656

Тел.: (8-4361) 25-780, , факс: (8-4361) 25-780, эл.адрес: Nars.Rs.@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.02.2022 г Яңа Арыш авылы №4

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль үткәргәндә тикшерү кәгазе рәвешен (контроль сораулар исемлеген) раслау турында

“Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында” 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 27 октябрендәге “Тикшерү кәгазьләре рәвешләре проектларын эшләүгә, эчтәлегенә, рәвешләрнең проектларын җәмәгатьчелек тикшерүенә (фикер алышуына), раслауга, куллануга, актуальләштерүгә, шулай ук тикшерү кәгазьләрен мәҗбүри куллану очракларына карата таләпләрне раслау турында” 1844 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль үткәргәндә тикшерү кәгазе рәвешен (контроль сораулар исемлеген) расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Яңа Арыш авылы, Мәктәп урамы, 30 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Яңа Арыш авыл җирлеге Башлыгы Х.С.Зарипов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Яңа Арыш авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2022 елның
28 февралендәге
4 номерлы карары белән
расланды

(Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге Башкарма комитеты бланкында рәсмиләштерелә)

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль үткәргәндә кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге)

1. Муниципаль контроль органының аталышы (исеме): Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге Башкарма комитеты.

2. Тикшерү кәгазе Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге Башкарма комитетының 28.02.2022 ел, №4 карары белән расланды.

3. Тикшерү үткәрү турында боерык (күрсәтмә) № ___, 2022 елның ___ ___________.

4. Тикшерүнең хисап номеры һәм тикшерүләрнең бердәм реестрында тикшерү хисап номерын бирү датасы (ЕРВК, ЕРКНМ мәгълүмати ресурсларда): ______________________________.

5. Тикшерү кәгазен тутырып тикшерү үткәрелә торган урын һәм (яки) юридик зат тарафыннан кулланыла торган җитештерү объектларына күрсәтү: ______________________________.

6. Юридик затның аталышы (исеме), индивидуаль эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса), ИНН (СТТН – салым түләүченең таныклау номеры): ______________________________.

7. Тикшерү үткәрүче вазыйфаи затның (затларның) вазыйфасы (вазыйфалары), фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта): ______________________________.

8. Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган сораулар исемлеге, юридик затның, индивидуаль эшкуарның тикшерү предметын тәшкил итүче мәҗбүри таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турындагы җаваплары, Һичшиксез, тикшерү предметы булып торган мәҗбүри таләпләрнең үтәлеше турында сөйли:

| № п/п | Сораулар исемлеге | Мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган хокукый актның реквизитлары | Җавап вариантлары | | | Искәрмә* |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Әйе | Юк | ярамаслык | |
| 1. | Биналарга, төзелмәләргә, корылмаларга, җир кишәрлекләренә һәм гомуми файдаланудагы башка территорияләргә янәшә территорияләрне үз-вакытында җыештыру тәэмин ителәме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 2. | Төзекләндерү элементларын карап тоту буенча таләпләр үтәләме: зарарлануларны үзвакытында бетерү, санитар чистарту, ремонт, буяу? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 3. | Каты коммуналь калдыкларны җыеп өю буенча таләпләр үтәләме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 4. | Кышкы һәм җәйге чорда территорияләрне җыештыру буенча таләпләр үтәләме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 5. | Карантин һәм агулы үсемлекләрне ачыклау, аларга каршы көрәш, аларны локальләштерү, чыганак урыннарын бетерү буенча чаралар үтәләме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 6. | Гомуми файдаланудагы җирләрдә төзелеш материалларын, күмер, утын, печән, салам, тирес һ. б. ларны өюгә тыю үтәләме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 7. | Төзелеш мәйданчыкларын киртә белән аерып бүлеп кую буенча таләпләр үтәләме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 8. | Төзелеш мәйданчыкларына килү (керү) юллары чисталыкта тотыламы? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 9. | Транспорт чараларын газонда яки башка яшелләндерелгән территориядә урнаштыруны тыю үтәләме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 10. | Үзвакытында техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт үткәреләме, шул исәптән биналарның, төзелмәләрнең һәм корылмаларның фасад элементлары? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 11. | Биналарның, төзелмә һәм корылмаларның су агызу торбалары, су агып төшү һәм су агызу җайланмаларының булуы һәм аларны төзек хәлдә тоту тәэмин ителәме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 12. | Фасад өслекләрен чистарту, юдырту һәм буяу эшләре алып барыламы, шул исәптән игъланнар, реклама мәгълүматы, чит-ят язулардан? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 13. | Түбәләрне һәм козырекларны вакытында кардан һәм боздан чистарту, боз, кар һәм боз сөңгеләреннән арындыру гамәлгә ашырыламы? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 14. | Инженерлык челтәрләре һәм корылмалары, линия корылмалары һәм коммуникацияләрнең төзек хәлдә тотылуы тәэмин ителәме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 15. | Яшел утыртмаларның сакланышын тәэмин итү буенча чаралар үткәрү гамәлгә ашырыламы? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 16. | Капиталь төзелеш, реконструкцияләү, техник яктан яңадан коралландыру объектларындагы эшләрне башкарганда яшел утыртмаларның сакланышы һәм (яки) аларны яңадан торгызу тәэмин ителәме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 17. | Җир милекчеләре, җир кишәрлекләреннән файдаланучылар тарафыннан коры һәм авария хәлендәге агачларны вакытында юк итү, корган һәм сынган ботакларны кисү, үсмер үрентеләрне җыеп алу үтәләме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 18. | Агачларны, куакларны юк итү (кисү), күчереп утырту өчен билет алу таләбе үтәләме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 19. | Төзелеш, ремонт эшләре башкарганда агачларны, куакларны юк итү (кисү), күчереп утырту өчен билет алу таләбе үтәләме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 20. | Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәтнамә) алу таләбе үтәләме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 21. | Транспорт чараларын эксплуатацияләү, хезмәт күрсәтү яки ремонтлау вакытында, йөк ташу яки төзелеш мәйданчыкларыннан чыкканда (тент яки каплау булмау аркасында) гомуми файдалану территорияләренең пычрануына юл куймау турында таләпләр үтәләме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 22. | Төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән янәшә | Татарстан Республикасы Балык | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | территорияләр чикләрен билгеләү тәртибе сакланамы? | Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 23. | Махсус янгынга каршы режим гамәлдә булган чорда янгын куркынычсызлыгының мәҗбүри таләпләре үтәләме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 24. | Малларны территориядә ирекле йөртүне тыю буенча таләпләр үтәләме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 25. | Авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм кошларын гомуми файдаланудагы территорияләрдә көтүгә юл куймау турында таләпләр үтәләме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 26. | Аз (акрын) хәрәкәтләнүче халык төркемнәренең биналарга, төзелмәләргә, корылмаларга , шулай ук җир кишәрлекләренә килү (керү) мөмкинлеге тәэмин ителәме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 27. | Инвалидларның объектларга тоткарлыксыз керә алуын тәэмин итү өчен җәмәгать билгеләнешендәге биналарга һәм корылмаларга үтүдә тротуарларга, пандусларга, баскычларга карата куелган таләпләр үтәләме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 28. | Җирлек территориясен чисталыкта тоту тәэмин ителәме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 29. | Гамәлдән чыгарылган коеларны көнкүреш чүп-чары белән күмүгә һәм аларны сәнәгать һәм каты коммуналь калдыклар туплау (ташлау) | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | чокырлары буларак файдалануга тыю үтәләме? | төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 30. | Төзелешләрдән, йорт биләмәләреннән чүп-чарны һәм балчык-туфракны билгеләнмәгән (тиеш булмаган) урыннарга илтеп ташлауны (бушатуны), җиргә күмүне тыю үтәләме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 31. | Урамнарда, мәйданнарда, чәчәклекләрдә, предприятие, оешма һәм торак йортлар ишегалларында сәнәгать калдыкларын һәм каты коммуналь калдыкларны, чүп-чар, яфракларны, ботак-санакларны кисүне, шулай ук чүп-чарны җыелма контейнерларда яндыруны тыю үтәләме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 32. | Вакытлы стационар булмаган объектларны, коймалар, блоклар һәм транспорт йөрүгә комачаулаучы башка киртәләрне үз белдегең белән торгызуны (урнаштыруны) тыю үтәләме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 33. | Транспорт чараларын ишегалларында һәм әлеге максатлар өчен билгеләнмәгән башка урыннарда юуны тыю үтәләме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 34. | Яшел утыртмалар территориясендә, шул исәптән газоннарда (кәстә) янгынга каршы кагыйдәләр нигезендә учак кабызуны (ягуны) тыю үтәләме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 35. | Кече архитектура формасы объектлары тиешле тәртиптә тотыламы, аларны ремонтлау һәм буяу эшләре алып барыламы? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 36. | Биналарны һәм корылмаларны эксплуатацияләү һәм ремонтлау техник эксплуатацияләү кагыйдәләре | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | һәм нормалары нигезендә башкарыламы? | төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 37. | Капиталь төзелеш объектлары милекчеләре, арендаторлары һәм кулланучылары тарафыннан законда каралган санитар-гигиена, архитектура-шәһәр төзелеше, янгынга каршы һәм эксплуатация таләпләре үтәләме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 38. | Капиталь төзелеш объектлары милекчеләре, арендаторлары һәм кулланучылары тарафыннан ремонт эшләре вакытында башкарыламы? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 39. | Капиталь төзелеш объектларында җир асты инженерлык коммуникацияләрен, юлларны, тротуарларны, яңгыр суы канализацияләрен, вакытлыча һәм даими коймаларны һәм башка кече архитектура формаларын реконструкцияләү, техник яктан яңарту, туфрак катламы яки юл капламалары (түшәмәләре) белән бәйле эшләрне башкару өчен җирлек администрациясе, инженерлык хезмәтләре, ЮХИДИ бүлекчәсе белән килешүләр бармы? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 40. | Эшләр башланганчы, җир эшләрен башкаручы оешма тарафыннан, гамәлдәге нормаларга туры китереп, якты тон төсләренә буялган стандарт типтагы киртәләр белән һәр казу (актару) урыны киртәләнәме (әйләндереп алынамы)? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 41. | Җир эшләре башкаручы оешма тарафыннан, эшләр башланганчы, күрү чикләнгән тәүлекнең караңгы вакытында киртәләүләр (коймалар) кызыл төстәге яктылык сигналлары белән тәэмин ителгәнме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 42. | Җир эшләре башкаручы оешма тарафыннан эшләр башланганчы юл билгеләре һәм стандарт типтагы күрсәткечләр куелганмы? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 43. | Җир эшләре башкаручы оешма тарафыннан, эшләр башланганчы, бөтен юлны ачу (актару) рөхсәт ителгән кишәрлектә әйләнеп узу өчен юл юнәлеше билгеләнгәнме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 44. | Җир эшләре башкаручы оешма тарафыннан эш башланыр алдыннан башкарылачак эшнең аталышын, эшләр башкаруга рөхсәтнамәне, башкарыла торган эшләргә җаваплы затларның телефон номерлары, фамилияләре, аталарының исемнәрен, эшнең башлану һәм тәмамлау вакытларын күрсәтеп щит (щитның үлчәмнәре 600 х 600мм) куелганмы? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 45. | Төзелеш мәйданчыгының әзер булу акты рәсмиләштерелгәнме (әзерлек эшләре тәмамланганнан соң)? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 46. | Төзелеш мәйданчыгына эшче документлар рәсмиләштерелгәнме (гамәлдәге закон таләпләренә туры китереп, объектны төзү, реконструкцияләү өчен аларның кирәк булу очрагында)? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 47. | Төзелеш мәйданчыгына төзелешкә рөхсәтнамә рәсмиләштерелгәнме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 48. | Мәгълүмат щитына түбәндәге мәгълүматлар кертелгәнме:<br>- объектның аталышы; | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | - төзүче, техник заказ бирүче, подрядчының аталышы, аларның адресларын һәм телефон номерларын күрсәтеп;<br>- объекттагы эшне башкару өчен җаваплы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, аның телефоны;<br>- объектны төзүнең күз алдында тотылган сроклары (башлануы, тәгәлләнүе);<br>- төзелешкә рөхсәтнамә реквизитлары? | районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 49. | Подрядчы тарафыннан төзелеш чорына төзелеш мәйданчыгы территориясен агымдагы карап тоту тәэмин ителгәнме, шул исәптән билгеләнгән график нигезендә калдыкларны, табигый һәм төзелеш чүп-чарларын җыю, чыгару? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 50. | Авыл җирлегенә кергән юлларга һәм урамнарга эшләр башкару территориясеннән һәм грунт юлларыннан машиналар, механизмнар, башка техника белән пычрак чыгаруны тыю сакланамы?; производство территориясеннән чыкканда авыл җирлеге урамнарына һәм юлларына машиналар һәм механизмнар белән пычрак чыгаруны кисәтү буенча чаралар күреләме?; грунт юлларыннан чыкканда транспорт чараларын йөртүчеләр тарафыннан җирлекнең пычрануын булдырмау буенча чаралар күреләме? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |
| 51. | Төзелеш эшләре нәтиҗәсендә бозылган төзекләндерү объектлары объектны кулланылышка кабул итүгә кадәр торгызылганмы? | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре | | | | |

***** **“ярамаслык”графасы тутырылган очракта "искәрмә" графасын тутыру мәҗбүри.***

Тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) белән таныштырылды:

_______________________________________________________________________________

(житәкче, башка вазыйфаи затның яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленең, индивидуаль эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

"______" _____________________, 20______ел ________________________________________

(имза)

Тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) белән танышудан баш тарту турында билге:

_______________________________________________________________________________

(тикшерү үткәрүче вәкаләтле вазыйфаи затның (затларның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

"______" _____________________, 20______ел ________________________________________

(имза)

Тикшерү кәгазе күчермәсен (контроль сораулар исемлеген) алды:

_______________________________________________________________________________

(житәкче, башка вазыйфаи затның яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленең, индивидуаль эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

"______" _____________________, 20______ел ________________________________________

(имза)

Тикшерү кәгазен (контроль сораулар исемлеген) алудан баш тарту турында билге:

_______________________________________________________________________________

(тикшерү үткәрүче вәкаләтле вазыйфаи затның (затларның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

"______" _____________________, 20___ ___г. ________________________________________

(имза)